# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның бишенче һәм алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"лагерьларда, шифаханәләрдә, шифаханә-профилакторийларда балаларны савыктыруга юлламалар бирү;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларны уку чорында бер укучыга көненә 3 сум күләмендә туклану белән тәэмин итү.".

**2 статья**

Әлеге Закон 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 14 октябре
№ 68-ТРЗ